СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Урнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**Үрнәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«14» октябрь 2019 ел** **№ 53**

**Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясына яраклаштырып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитетының «Референдум үткәрүдә инициатива күрсәтү турында» 2019 елның 10 октябрендәге 12 номерлы карары, Үрнәк авыл җирлеге Советының «Референдум үткәрүдә инициатива күрсәтү турында» 2019 елның 10 октябрендәге 51 номерлы карары нигезендә Үрнәк авыл җирлеге Советы КАРАР бирде:

1. 2019 елның 01 декабренә Үрнәк авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
"2020 елда сез Үрнәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге формада белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм 1 нче группа инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

1.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшләре алып бару:
- урам-юл катламы нигезен салып вак таш түшәү һәм су агызу торбалары урнаштыру:

**Үрнәк бистәсе**, Урман урамыннан 50 нче йортка бару юлы, Күпер урамыннан 11 нче йортка бару юлы, Нарат урамыннан Тылаңгыр авылына бару юлы -50 м; **Түбән Пошалым авылы**,Пионер урамы,2 нче йорттан зиратка кадәр, 8нче йорттан 19 нчы йортка кадәр; **Югары Пошалым авылы,** Мичурин урамы, 5 нче йорттан 12 нче йортка кадәр, зиратка кадәр; **Урта Пошалым** авылы, Сәйдәшев урамы, 17 нче йорттан 23 нче йортка кадәр; **Көтек авылы**, Гагарин урамы, 37 нче йорттан 42 нче йортка кадәр; **Казанбаш авылы**, Мәктәп урамы, 96 нчы йорттан 99 нчы йортка кадәр, Яшьләр урамы, 126 нчы йорттан 134 нче йортка кадәр, Киров урамыннан 62 нче йортка керү юлы; **Четыре двора авылы**, Күпер урамы, 5нче йорттан 6 нчы йортка кадәр; **Апайкин Гарь авылы,** Үзәк урам, 32нче йорттан 38 нче йортка кадәр; **Казанка авылы**, Җиңү урамы, 19 нчы йорттан 22 нче йортка кадәр; **Күлтәс авылы**, съезд авылы, 15-17 нче йортлар. Г. Кәбиров урамының 15-17 нче йортларына бару юлы; **Гарталовка авылы**, Урман урамы, 9 нчы йорттан 11 нче йортка кадәр;

-юл-урам челтәренә тигезләү катламы ясау:

**Үрнәк бистәсе**, Нарат ур.-200м, Болын ур.-100м, Бакча ур.-70м. Көнчыгыш ур.-100м, Төньяк ур.-100 м, Көнбатыш ур.-100 м, **Күлтәс авылы**, Мөбарәкшин ур. - 100 м, Г. Кәбиров ур. - 100 м, бертуган Зыятдиновлар ур. - 100м, **Иске Төрнәле** авылы, Комсомол ур.-100м, **Югары Пошалым авылы**, Тукай ур.-200 м;

- торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту.

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Казанка авылында урам утлары челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;

-Алга-Көек, Апайкина Гарь, Кече Төрнәле, Күлтәс авыллары янында рөхсәтсез ясалган чүплек урыннарында җирләрне торгызу;

–Үрнәк (ике чишмә), Алга Көек, Тылаңгыр, Югары Пошалым (ике чишмә) торак пунктларында чишмәләрне ремонтлау һәм төзекләндерү, материаллар сатып алу.

- Күлтәс, Көтек, Иске Төрнәле авылларында агачларны санитар кисү һәм чыгару.

- Үрнәк бистәсендә балалар мәйданчыгына кече архитектура формалары сатып алу (ике данә).

- Кече Төрнәле авылы янында Казансу елгасы аша җәяүлеләр күперенә баскыч урнаштыру.

3. Җирләү хезмәтләре оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту:

- Түбән Пошалым, Алга Көек, Күлтәс авыллары зиратын чисталыкта һәм тәртиптә тоту өчен чүп җыю контейнерлары, үлән чапкычлар, бензопила, генератор сатып алу;

- Казанбаш авылы зиратының коймасын буяу (лак-буяу материаллары сатып алу);

- Түбән Пошалым авылы зиратына кирәк-яраклар тоту өчен бина ясау;

- Апайкина Гарь авылы зираты территориясендә агачларны санитар кисү һәм чыгару.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм халык күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: ТР, Арча районы, Үрнәк бистәсе, Урман урамы, 44а йорты; Татарстан Республикасы, Арча районы, Казанбаш авылы, Киров урамы, 49 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Урта Пошалым авылы, Вахитов урамы, 15 йорт.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы Камалетдинов И.Р.

СОВЕТ УРНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ